Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Дымтамак авыл җирлегенең Алабакүл торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

№ 10 07 ноябрь 2025 ел

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлегенең Алабакүл торак пунктындагы гражданнар җыены нигезендә,

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлегенең Алабакүл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Федерациясе Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2026 елда 200 (ике йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юлларга:

– торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Алабакүл торак пунктының юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (реконструкция, асфальт салу, ремонтлау, ташу, төзелеш материалларын сатып алу, эшләр өчен шартнамә буенча түләү).

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Ютазы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Дымтамак авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Димтамак авыл җирлеге башлыгы Җ.Ә.Хөснетдинов